Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге составына керүче
Саескан Тавы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

17 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 17 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Саескан Тавы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Елга авылы суүткәргеч магистраленең су задвижкаларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
- авыл җирлеге торак пунктларындагы урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
- Олы Елга авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап тотуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);
- Саескан Тавы авылында контейнер мәйданчыгы ясау һәм төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Олы Елга авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу, урнаштыру, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);
- суүтем башнясын сатып алу, монтажлау һәм урнаштыру (килешү буенча эшләрне түләү);
- мотопомпа өчен янгын җиңнәре сатып алу.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 62 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 34 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 34 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Саескан Тавы авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Саескан Тавы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

–

– Олы Елга авылы суүткәргеч магистраленең су задвижкаларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– авыл җирлеге торак пунктларындагы урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– Олы Елга авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап тотуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);

– Саескан Тавы авылында контейнер мәйданчыгы ясау һәм төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу, урнаштыру, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);

- сусаклагыч башнясын сатып алу, монтажлау һәм урнаштыру (килешү буенча эшләрне түләү);
- мотопомпа өчен янгын җиһазларын сатып алу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Мингалеев И.Н.

СОВЕТ БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000235 ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ